СОВЕТ ВОЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ВОЙКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08.04.2026 с. Войкино № 18

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Войкино авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Войкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 21.08.2023 ел, №51 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Войкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына туры китереп, 2026 елның 06 апрелендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Войкино авыл җирлеге Советы

**Карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Войкино авыл җирлеге Советының 21.08.2023 №51 карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Войкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертергә (Кушымта).
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (https://alekseevskiy.tatarstan.ru/),Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Войкино авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе** **Н.П. Шабутдинова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Войкино авыл җирлеге Советының
08.04.2026 ел, № 18
карарына кушымта

**Бүлек 21. Йорт хайваннарын һәм кошларын асрау**

Статья 79

1. Җәмәгать урыннарында озатып йөрүче затлардан башка торучы күзәтүчесез хайваннар тотылырга тиеш.

2. Күзәтүчесез калган хайваннарны аулауны мондый хайваннарны тапкан махсуслаштырылган предприятие яисә башка зат җирле үзидарә органнары белән төзелгән килешү буенча башкарырга мөмкин.

3. Хуҗасыз калган хайваннарны аулау чараларын гамәлгә ашыру хайваннарга карата гуманлы мөнәсәбәт һәм иҗтимагый әхлак нормаларын үтәү принципларына нигезләнә.

4. Рөхсәт ителми:

1) хайваннарны судның тиешле карарыннан башка фатирлардан һәм хосусый йорт биләмәләре территориясеннән тартып алырга;

2) кибетләр, даруханәләр, коммуналь хезмәт күрсәтү предприятиеләре янындагы этләрне бәйдән ычкындырырга;

3) ветеринария органнары тәкъдименнән башка, тоту тозакларын һәм башка чараларны файдаланырга.

4) торак массивлар, җәмәгать урыннары һәм социаль объектлар территориясендә хуҗалары булмаган хайваннарны өстәмә тукландыру. Искәрмә - тыю җирле үзидарә органы тарафыннан хуҗасыз хайваннарны ашату өчен махсус оештырылган урыннарга кагылмый.